ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 304 от «26» 07 2023 г.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районында
үлем- китемнәр буенча ведомствоара
комиссия турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Мамадыш районы халкының мониторингын оештыру, үлем - китем сәбәпләрен өйрәнү һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә аны киметүгә юнәлдерелгән нәтиҗәле чаралар күрү максатларында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1.Түбәндәгеләрне расларга:

- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында үлем- китемнәр буенча ведомствоара комиссия составын (килешү буенча) (1 нче кушымта);

- Татарстан Республикасы Мамадыш районында үлем- китемнәр буенча ведомствоара комиссия турында Нигезләмә (2 нче кушымта);

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Н.Ш.Фатыховка йөкләргә.

Җитәкче О.Н.Павлов

0000011897

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
«26» 07 2023 ел, № 304
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында үлем - китемнәр буенча ведомствоара комиссия составы

| | |
|---|---|
| Фатыхов Н.Ш. | Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - комиссия рәисе; |
| Гарипов Р.З. | «Мамадыш үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы - комиссия рәисе урынбасары; |
| Гилаев Б.М. | Мамадыш үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибының урынбасары - комиссия секретаре; |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Сәмигуллин Р.Р. | Мамадыш муниципаль районы Башлыгы урынбасары; |
| Усачев Л.Б. | Эчке эшләр министрылыгының Мамадыш районы буенча башлыгы; |
| Горбунов А.П. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Мамадыш муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге җитәкчесе; |
| Шайхутдинова Л.А. | Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының ЗАГС бүлеге башлыгы. |

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
«26»____07___2023___ел, №304
карарына 1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Мамадыш районында үлем- китемнәр буенча ведомствоара комиссия турында Нигезләмә.

### 1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында үлем-китемнәр буенча ведомствоара комиссия (алга таба - комиссия) Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән төзелә.

1.2. Комиссияне Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары җитәкли.

1.3. Комиссия составына җирле үзидарә органнары вәкилләре, шулай ук килешү буенча хокук саклау органнары, сәламәтлек саклау, социаль яклау учреждениеләре, мәшгульлек үзәге вәкилләре кертелә. Комиссия әгъзалары үз эшчәнлекләрен җәмәгать башлангычларында гамәлгә ашыралар һәм аның утырышларында шәхсән катнашалар. Комиссия утырышында прокуратура, суд, эшмәкәрлек структуралары,җәмәгать оешмалары вәкилләре, оешмалар җитәкчеләре һәм сәламәтлек саклау учреждениесе белгечләре чакырыла ала.

### 2. Комиссиянең бурычлары.

2.1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында халыкның үлем сәбәпләренә анализ ясау.

2.2. Халык үлемен стабильләштерүгә һәм киметүгә, медицина ярдәменең сыйфатын яхшыртуга һәм оештыруга юнәлдерелгән ашыгыч һәм озак вакытка идарә итү карарларын эшләү һәм кабул итү.

### 3. Хокук һәм бурычлар.

3.1. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

- оешмалар һәм учреждениеләр тарафыннан, аларның ведомствога каравына һәм оештыру-хокукый формасына карамастан, үтәлергә тиешле карарлар кабул итәргә;
- комиссия эше өчен кирәкле материаллар һәм мәгълүматны җитәкчеләрдән һәм учреждениеләрдән, аларның ведомствога каравына һәм оештыру-хокукый формасына карамастан, сорарга.

3.2. Комиссия бурычлы:

- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында, шул исәптән хезмәткә сәләтле яшьтәге халыкның үлем күрсәткечләренә динамик анализ ясарга.
- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында халыкка медицина ярдәме күрсәтүгә анализ ясарга.

## 4. Комиссия эшен оештыру

4.1. Комиссия утырышлары кирәк саен үткәрелә, ләкин кварталга кимендә 1 тапкыр уздырыла.

4.2. Комиссия утырышы комиссия әгъзаларының гомуми составының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашында хокуклы дип санала. Комиссиянең барлык карарлары комиссиянең гомуми составындагы күпчелек тавыш белән кабул ителә.

4.3. Комиссия секретаре комиссия утырышының билгеләнгән датасына кимендә 3 көн кала Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында үлүләрне анализлау статистик материалын карала торган мәсьәлә нигезендә бирә.

4.4. Комиссиянең чираттан тыш утырышы комиссия рәисенә нигезле тәкъдим биреп, комиссия әгъзасы тарафыннан инициацияләнергә мөмкин.

4.5. Чираттан тыш утырыш үткәрү турында карарны комиссия рәисе кабул итә.

4.6. Комиссия утырышлары ачык утырышлар һәм ябык утырышлар формасында да үткәрелергә мөмкин. Үткәрү формасы турында карар комиссия әгъзаларының гомуми составының күпчелек тавышлары белән кабул ителә.

4.7. Комиссия утырышлары «Мамадыш үзәк район хастаханәсе» ДАССУ да да, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетында да үткәрелергә мөмкин.